Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 4 феврале № 6/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, 2020 елның 5 октябрендәге 3 номерлы Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге советы 2014 елның 7 июлендәге 40/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территорияләрен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Торак йортлар төзү зонасы» Ж1 территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм кадастр номеры 16:42:080302:145, мәйданы 2515 кв.м. булган, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Татар Талкышы авыл җирлеге, Кызыл Ялан авылы, Яр Буе ур., з/у 27Д адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге территориясен «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасы» СХ1 төзелеш зонасына кертү өлешендә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Татар Талкышы
авыл җирлеге башлыгы М.М. Вәлиев

2021 елның 4 февралендәге 6/2 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

